# Әлфирә Абзал кызы Низамова



Әлфирә Абзал кызы Низамова 1953 елның 4 июлендә Әгерҗе районы Исәнбай авылында туып үскән. Кабатланмас шигъри моңы белән күңелләрне иркәләүче, илаһи тавышы белән җаннарны уятучы, милләт дип өзгәләнеп яшәүче, татар теле, туган телебезне матур шигырьләре аша безгә җиткерүче Татарстан һәм Удмуртия Язучылар берлеге әгъзасы, “Язмышым канатында” (2003), “Кояш исе” (2008), “Һәр бәйрәмнең үз гаме” (2012), “Көзге күкрәү”((2013) исемле китаплар авторы, Риза Шәфи, Тажи Гыйззәт исемендәге премияләр лауреаты, мәдәнияттәге казанышлары өчен күкрәк билгесе иясе, 1998 елдан “Күңел чишмәләре”әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы Әлфирә Низамова районыбызның тагын бер горурлыгы.

Әлфирә Низамова кечкенәдән шигырьләр язса да, аны иҗат бишегенә салучылары “Яңарыш” хезмәткәрләре һәм якташлары Габдулла Галиев һәм Чыңгыз Мусин була. Нәкъ алар тәкъдиме белән беренче шигырьләр җыентыгы нәшер ителә. Әлфирә Низамова күп еллар авыл хуҗалыгы тармагында эшләгән. Әмма иҗат белән шөгыльләнүче, сәнгать һәм мәдәнияткә тартылучы ханымны авыл клубын җитәкләргә тәкъдим итәләр. 27 елдан артык гомерен мәдәнияткә багышлый. Мәдәният өлкәсендәге һәм иҗаттагы уңышлары өчен Татарстан һәм Удмуртия республикаларының Мактау грамоталарына, мәртәбәле дипломнарына, рәхмәт хатларына лаек.

“Яңарыш” һәм “Әгерҗе хәбәрләре” газеталарының актив хәбәрчесе.

Бүгенге көндә иҗатына илһам биреп, радио – телевидениедә, сәхнәләрдә, Татарстанның халык артисткасы Хәния Фәрхи, Чулпан Зиннәтуллина, Владимир Мироваев, Ландыш Баһави, Диләрә Шәрипова, Язгөлем Гыймазетдинова, Фәнис Арсланов башкаруында җырлары яңгырый Әлфирә Низамованың. Әйе, аның шигырьләре җыр кебек җырлап, җиңел укыла. Бәйрәмнәр, кичәләр уздыру өчен махсус шигырьләр дә яза, кичәләрнең сценарийларын туплап бара. “Һәр бәйрәмнең үз гаме” исемле сценарийлар җыентыгы авыл китапханәләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, укытучыларга таратылды һәм киң кулланыш тапты.

Әлфирә Абзал кызы Низамовага без бары иҗат һәм гаилә уңышлары, балалар изгелеге телибез. Шигырьләре туып, китаплары басылып торсын.

*Әгерҗе районы*
*“Күңел чишмәләре” иҗат берләшмәсе җитәкчесе*
*Нурмөхәммәтова Чулпан Рәвил кызы*